ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

МАРТ,
2017 нче ел

№6 (20)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**





**8—Халыкара хатын-кызлар көне**

**21— Нәүрүз бәйрәме**

## НАЗЛЫ ТУТАШ, ЗАТЛЫ ХАНЫМНАР!

Яшәешебезнең бизәге булган хатын-кызларыбыз бәйрәме якынлашкан күңелле бер мизгелдә һәр ел саен бар җиһан җанлана, табигатьтә яз сулышы бөркелә. Әйтерсең асыл затларыбыз күңеленнән сирпелгән җылылык ак карларны эретә, сихри дөньяга сафлык, наз, илаһилык, ямь өсти.

Хатын-кыз... Бу сүздә никадәр мәгънә, никадәр төрлелек ята. Хатын-кыз дию кемнеңдер күзалдына нурлы йөзле әнисе, уңган-булган хатыны, ә кемнеңдер җылы куллы сөйгәне килеп басадыр. Әмма аларны берләштерүче бер мөһим сыйфат бар: дөнья йөзендәге иң нәфис, иң хисле, иң гүзәл затлар алар!

Сезне гүзәллеккә, чибәрлеккә, мәрхәмәтлеккә, түземлеккә дөньяда тиңнәре булмаган гүзәл, сөйкемле хатын-кызларыбыз бәйрәме – 8 нче март – бәйрәме белән тәбрик итәбез. Барыгызга да нык сәламәтлек, эшегездә зур уңышлар, күңел тынычлыгы, гаилә тигезлеге, матур киләчәк телибез. Һәр аткан таң сезгә бәхет китерсен.

**Мәктәп администрациясе**

### Укытучы ир-атларының хатын-кызлар турында фикерләре

**<u>–Бу дөньяда хатын-кызсыз яшәү мөмкинме?</u> Рәис Азатович, физика укытучысы:**

–Янәшәбездә хатын-кызлар булмаса, җирдә яшәүнең мәгънәсе, тәме булмас иде. Алар безнең балкыр кояшыбыз, мәңге сүнмәс йолдызларыбыз. Хатын-кызлар без, ир-атлар яклаучысы, саклаучысы итеп карарга өйрәнгән, шушы бурычыбызны алар алдында үти алсак иде. Аларның күңел хисләрен аңлап, һәрвакыт хөрмәт белән карап яшәргә булсын!

**<u>–Ничек уйлыйсыз, хатын-кыз, хаклыкта да "көчсез"ме?</u> Айрат Каимович, физик тәрбия укытучысы:**

–Бүген кайсы гына өлкәне алма, мәгариф, сәламәтлек һәм башкасы–күпчелегендә хатын-кыз хезмәт куя. Шәхсән үзем дә, шундый коллективта эшлим һәм гүзәл затларыбызның бөтен төр эшне зур җаваплылык тоеп башкара алулары белән горурланам. Йөкнең күбрәк өлешен үзебезгә алып, хатын-кызларыбызга кадер-хөрмәтне арттырасы иде.

**Бу санда:**

| | |
|---|---|
| Өч, ике, бер… тәгәрә! | 2 |
| Прием в юнармейцы | 3 |
| Якыннан танышыйк! | 4 |
| Син мине күрәсеңме? | 4 |
| Көлке хикмәте | 5 |
| «Үз юлым» конкурс– лабораториясе | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |

# ӨЧ, ИКЕ, БЕР... ТӘГӘРӘ!

***Ике тәгәрмәчле дустыбызга яңа алмаш үсеп килә. Бу электромотоцикл.***

- Мотоцикл асфальттан да, чирәмле җирдән дә йөри ала. Тротуардан барганда, җәяүлеләргә комачауламас өчен, тизлекне бераз гына киметергә туры килә.
- Аның белән кыш көне дә йөреп була, ул боздан бик шәп тәгәри. Ә инде хәзер шәһәр тротуарларында кышын бозның бик сирәк очравын исәпкә алсак, җәйге йөрү рәвешеннән әллә ни аерылмый да.
- Яңгыр да, кар да аңа киртә була алмый. Мотоциклга су бөтенләй куркыныч түгел.
- Әлегә мотоцикл, кеше күзе күнекмәгән могҗиза булгангамы, шактый кыйбат тора: 30дан 100 меңгә кадәр. Ләкин ышаныгыз, 3-4 елдан аларның бәясе шактый төшәчәк.

Электромотоцикл буларак, ул, әлбәттә, зарядкасыз йөри алмый, аккумуляторының за-





Ученикам, учителям и сотрудникам школы прекрасно известны действия при срабатывании пожарной сигнализации. Вот и сегодня, во время тематических классных часов прозвучала сигнализация. Все эвакуировались из здания по нужным пожарным выходам.

## Прием в юнармейцы



Юнармейское движение создалось в соответствии с решением Президента РФ от 30 декабря 2015 года, в качестве одного из направлений деятельности общероссийской общественно-государственной детско-юношеской организации «Российское движение школьников». Главная ее цель-это развитие и совершенствование системы военно-патриотического воспитания молодёжи.

Когда в зал внесли флаги РФ, РТ , отряд юнармейцев поднялся на сцену. Прозвучали гимны РФ и РТ. Ребята произнесли слова клятвы, получили напутствие и поздравления.

**На мероприятии приняли участие начальник штаба подполковник Мазияров И.Ф., директор молодежного формирования «Форпост» Садретдинов А.Х., глава Фомкинского сельского поселения Абдрахманов Р.Х.**





**Укучыларның сорауларына инглиз укытучысы Садретдинова Гөлназ Ринат кызы җавап бирә.**

**- Гөлназ Ринатовна, укытучылык һөнәрен сайларга кем этәргеч ясады?**

Төп белгечлегем буенча мин татар теле һәм әдәбият укытучысы. Өстәмә рәвештә инглиз телен өйрәндем. Тел үзләштергәндә иң мөһиме кызыксынучан булырга кирәк.

**– Бүген авыл укытучысы алдында нинди проблемалар тора?**

– Шәһәр мәктәпләре белән чагыштырганда, бәлки, авыл мәктәпләренең матди яктан тәэмин ителеше бер дәрәҗәдә түгелдер. Кирәкле дәреслекләр соңарып килә. Ләкин шәһәр белән авыл укытучысын мин кискен каршы куймас идем, без дә нәкъ шул эшне башкарабыз.

**– Сез «Алгарыш» грантында җиңеп, бер айга Англиягә стажировкага бардыгыз, бәйгедә катнашырга гариза биргәндә, җиңүегезгә ышанган идегезме?**

- Җиңәм дип бармадым. Мәктәптәге хезмәттәшләрем, укучыларым минем өчен җан атып торды. Аларның ярдәмен һәрвакыт тоеп килдем.

**— Укытучылары чит илгә барып кайткач, укучылар инглиз телен икеләтә тырышып өйрәнә башлаганнардыр инде?**

– Чыннан да шулай. Авыл укучыларының хыяллары зурдан түгел бит аларның. Ә монда фото, видеоларны күргәч, алар да чит илгә барып кайту булмас эш түгел икәнен аңладылар.

**- Укучылар өчен авыл мәктәбендә белем алуның уңай һәм тискәре яклары нидә дип уйлыйсыз?**

– Яңа гына безнең мәктәпкә шәһәрдән бер бала укырга кайтып: «Сездә рәхәт, һәр балага игътибар җитә икән!» – дип шаккатырды. Авылда бала саны аз булгач, укытучы һәр балага индивидуаль карый. Укучылар һәр дәрескә әзерләнеп йөри. Авыл баласы эш белән дә чыныгып үсә.

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

# СИН МИНЕ КҮРӘСЕҢМЕ?

***«Бер тапкыр күрү йөз тапкыр ишетүдән артык». Мондый сүзләрнең хаклыгына үзеңнең дә кат-кат инанганың бардыр. Алай гына да түгел, кемнедер нәрсәгәдер ышандырасың килгәндә: «Үз күзләрем белән күрдем», – дип ант та итәсеңдер әле…***

**Куркыныч уеннар һәм куркынычсыз хезмәт**

Күзләрне җәрәхәтләргә мөмкин булган уеннар уйнамагыз, дигән кисәтүләрне йөз тапкыр ишеткәнегез бардыр инде. Рогатка, кулдан ясалган яисә сатып алынган уенчык пистолетлар һәм җәяләр, төрек кылычлары һәм мушкетер шпагалары, карбид һәм дары белән тәҗрибәләр ясау – әнә шундыйларга керә. Тик малайлар һаман да алдагы буын яшүсмерләренең хаталарын кабатлый тора. Мин сездән үтенеп сорыйм: якында гына урнашкан электр лампочкаларын кабызганда читкәрәк борылыгыз! Челтәрдәге лампочканы селкеткәләп, өзелгән спирален кабат ялгарга тырышмагыз! Андый чакта һичьюгы күзлек киегез – кояштан саклый торганы да ярый. Төрле тыгызлыктагы кояш күзлекләре күзне нур энергиясе белән пешүдән: электр белән эретеп ябыштыргандагы ультрафиолет нурлардан, контакт чыбыкларның кыска ялганышыннан, тау һәм үзәнлекләрдәге кар ятмасы чагылышыннан (кар офтальмиясе), ультрафиолеттан да саклый. Электр белән эретеп ябыштыруга, гомумән, махсус саклагычсыз карарга ярамый. Химия, хезмәт кебек фәннәр буенча практик дәресләрдә, мәктәп остаханәләрендә һәм ремонт эшләре вакытында саклагыч яисә гади күзлекләр файдалану мәслихәт.

## Күрү сәләтен саклау кагыйдәләре

Авыруларга бирешмәс өчен, организмыңны чыныктыр. Спортның башыңа зыян китермәстәй барлык төрләре дә күзләреңә файдалы булачак. Ә баш бәрелү, киресенчә, күрә карауны арттырачак кына. Сүрән яктылыкта уку-язу белән шөгыльләнмә, шулай ук күзләреңне көчле яктылык чагылдырудан саклан. Лампочкаңның егәрлеге 60 ваттан да кимрәк булмасын. Китабыңны яисә дәфтәреңне күзләреңнән 30-35 см ераклыкта тот. Китапны авыш торткычка куеп укысаң, тагын да яхшырак. Язганда, яктылык сул ягыңнан төшсен. Ятып яисә транспортта барганда укыма.

## Компьютерда эшләү кагыйдәләре

1. Компьютер каршында утырганда, башыгызны бераз гына алга таба иеп, туры утырыгыз.

2. Компьютерны почмакка урнаштырыгыз, чөнки, экранга караганда, аның арткы ягыннан нурланыш көчлерәк.

3.Монитор экранының өске кырые күзләр белән бер тигезлектә, ә ара 45тән 75 сантиметрга кадәр ераклыкта булсын. Мониторга кояш нурлары турыдан-туры төшмәсен.
4. Компьютерда көненә 2 сәгатьтән артык эшләргә ярамый, һәр 30 минут саен тәнәфес ясап алырга кирәк.
5. Күзе начар булган кешегә комьютерда эшләгәндә күзлек яисә линза кию мәҗбүри.

## Юлда игътибарлы булыгыз!



Начальник Нурлатского филиала ГКУ «Дирекция финансирования научно-образовательных программ БДД РТ» Гульфия Харисовна Гималтдинова провела беседу с обучающимися о правилах дорожного движения в целях безопасности жизни детей на дорогах во время весенних каникул.

## Чаңгы сезоны ябылды

11 нчы мартта аэропорт территориясендә узан чаңгы сезонын рәсми рәвештә ябуга багышланган район ярышларында 6 яшьтән 70 яшькәчә 1200 спорт сөючe катнашты. Ярышлар 5 дистанциядә узды. Массакүләм чарадан безнең мәктәп укучылары Гараев Фәиз, Вильданов Рәзил, укытучыларыбыз Хузахметова Гөлчәчәк, Галлямова Гөлүсә, Гумерова Флүсә, Гирфанова Ралия һәм директорыбыз Хәлим Салихович та бик теләп катнаштылар. Җиңүчеләргә грамоталар һәм медальләр тапшырылды.

## Ура каникуллар!

Укучыларның язгы каникулын күңелле һәм файдалы үткәрү максатыннан мәктәбебездә аерым план нигезендә эш алып барылды: ял булуга карамастан, мәктәптә балаларның шат авазы тынып тормады. Күңелле мәшәкатьләре, яңа чаралар, кызыклы очрашулары белән язгы каникул үтеп тә китте. Яңа идеяләр белән рухланган, ял итеп, көч туплаган укучыларыбыздан яңа җиңүләр, уңышлар көтеп калабыз.

**31 нче март көнне, Нурлат шәһәренең Халыклар дуслыгы йортында «Без бергә» балалар халык иҗаты фестиваль – конкурсының муниципаль этабы үтте.**




Конкурста алты номинация билгеләнгән иде: хореография, халык җыры, халык җыры ансамбле, инструменталь ансамбль, әдәби уку, мода театры. Безнең укучыларыбыз Шарафутдинова Әдилә, Хисматова Зәринә һәм “Балачак” ансамбле бик уңышлы чыгыш ясадылар. Шарафутдинова Әдилә нәфис сүз буенча 1 урынны яулады, ә “Балачак” ансамбле үз номинациясендә II урынга лаек булды.



# Көлке хикмәте



*****

Имтихан. Билетларны таратып бетергәннән соң укытучы:

- Әзерлек өчен сезгә күпме вакыт кирәк булыр?

- 30 минут.

- Яхшы. 40 минуттан соң көтмәгәндә килеп керермен.

****

Балалар лагеры. Кич. Беркем дә йокламый, кем телефонда уйный, кем смс яза, кем… Кыскасы, берәүнең дә телефоннан аерыласы килми. Тәрбияче бер-ике тапкыр кисәтә дә:

— Булды. Житте. Телефоннарыгызны жыеп бирегез!

Балалар теләр-теләмәс кенә телефоннарын бирергә мәҗбүр булалар.

Балалар лагеры. Таң алды. Тәрбиячекенең рәнҗүле хәлсез тавышы:

— Кабәхәтләр!.. Юньсезләр…

Телефоннарын бирер алдыннан балалар будильник кушкан икән. Кайсы – сәгать бергә, кайсы – беренче яртыга, кайсы – икегә…

* * *

–Нишләп синең кулларың пычракка баткан, ә ике бармагың чип-чиста?

–Мин сызгырырга өйрәндем.

****

Яңа татар үзенең малаен абруйлы мәктәпнең 1 нче сыйныфына урнаштырырга дип алып килә. Директор:

– Йә, энекәш, синең исемең ничек?

Малай дәшми

– Сиңа ничә яшь?

Дәшми.

– Үскәч кем булырга телисең?

Дәшми.

– Гафу итегез, – ди директор яңа татарга, – сезнең улыгыз сөйләшә дә белми, шуңа күрә кабул итә алмыйбыз.

– Ул юри шулай кылана, – ди яңа татар, аңгыра малаеның баш түбәсенә шапылдатып. – Бер атнадан тагын кереп чыгарбыз әле.

Бер атнадан директор малай белән тагын әңгәмә корып җибәрә:

– Синең исемең ничек?

– Вәли! –

Сиңа ничә яшь!

– Сигез! –

Үскәч кем булырга телисең?

– Космонавт!


– Ә нишләп космонавт?

– Вәли

-Нәрсә?!

– Сигез!

## Үз юлым
## КОНКУРС-ЛАБОРАТОРИЯСЕ



“Калеб” яшьләр буыны җыены, Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм “Ялкын” журналы тарафыннан оештырылган **«Үз юлым – Своя строка» Республикакүләм иҗади конкурс-лабораториясе** тәкъдим итә!

Арабызда ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ ӘКИЯТ, ХИКӘЯ, ПОВЕСТЬ, РОМАН ЯЗУЧЫ ЯШЬЛӘРнең күп булуына сөенәсе генә кала. Акрынлап сайтыбызда конкурсантларның проза әсәрләре белән укучыларны да таныштырып барабыз.

Әйдәгез әле, проза язуда беренче адымнарын ясаган яшьләргә көч һәм этәргеч бирик. Аларның хезмәтләре белән танышыгыз һәм түбәндәге сораштыруда үз фикерегезне белдерегез!



**Бу конкурста 8 нче сыйныф укучылары Әһлиуллин Аяз «Бүләк» һәм Гафурова Алия «Хыяллар искерәме?» хикәяләре белән катнаша. Аларга уңышлар телик һәм тавыш бирергә дә онытмыйк.**



## Хөрмәтле

## Сафиуллина Резеда Дамировна!

Сезне алтын юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!







### Март аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Хәйруллина Әдилә, Закиров Рәзил, Гайсина Гөлшат, Галиуллин Рәмис, Вәлиәхмәтова Әлинә!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хәйбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова Алсинә, Ахметова Нәзилә.